**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ БОЛГАЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2020 ел ,20 гыйнвар №129

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Олы Болгаер авыл җирлегендә “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле узидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турындагы” карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлегенең 2018нче елның 5нче апрелендәге "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турындагы" 55 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) махсус эш режимы өчен вазыйфа буенча окладның 25 проценты күләмендә айлык компенсация түләүләре.

Махсус эш режимы өчен айлык компенсация муниципаль хезмәтнең югары һәм төп вазыйфаларын, шулай ук нормага салынмаган эш көне булган муниципаль хезмәтнең бүтән вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә бирелә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Интернет телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Олы Болгаер авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Болгаер авылы**
**җирлеге Башлыгы** **З.И.Сәйфуллина**